ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 419-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 419-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2023 елның 16 июненә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2023 елның 16 июленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 1995-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.Н. Шәфигуллин,
Р.Р. Гайзатуллин,
М.Һ. Галиев
тарафыннан кертелгән

**«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11; 2010, № 12 (II өлеш); 2014, № 4; 2016, № 7 – 8, Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяның 3 өлешендә «яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү» сүзләрен «, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү яисә муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү» сүзләренә алмаштырырга;

а) 10 статьяның $2^1$ өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$2^1$. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын концессия килешүе яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү нигезендә төзү, яңарту һәм эксплуатацияләү түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып башкарыла:

1) мондый мәгълүмат системасы операторы функцияләре тиешле килешүдә каралган чикләрдә, күләмнәрдә һәм срокларда концессионер яисә хосусый партнер тарафыннан башкарыла;

2) концессия килешүе яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү гамәлдә булган чорда концедент яисә хосусый партнер концессионерның яисә хосусый партнерның мондый мәгълүмат системасындагы һәм тиешле килешүләр буенча үз йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле мәгълүматтан файдалана алуын тәэмин итә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

**«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында әзерләнде.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 604-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2.2 өлешенә муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү нигезендә мәгълүмат системасын төзү, яңарту һәм эксплуатацияләү каралган үзгәреш кертелгән. Бу очракта мәгълүмат системасы операторы функцияләре мондый килешүдә каралган чикләрдә, күләмнәрдә һәм срокларда хосусый партнер тарафыннан башкарыла.

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында» Федераль законның 14 һәм 14.1 статьяларына һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон белән яңа нигезләмә кертелде. Анда дәүләт мәгълүмат системасын концессия килешүе яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү нигезендә төзегәндә, яңартканда һәм эксплуатацияләгәндә концессия килешүе яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү гамәлдә булган чорда концедент яисә хосусый партнер концессионерның яисә хосусый партнерның мондый мәгълүмат системасындагы һәм тиешле килешүләр буенча үз йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле мәгълүматтан файдалана алуын тәэмин итә диелгән.

Югарыда күрсәтелгән федераль законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә закон проектында «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына төгәлләштерә торган үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив-хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.